РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

САБИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

СОВЕТ САТЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

422070, Республика Татарстан, Сабинский район,
С.Сатышево, ул. Ленина, 17Б
тел. (8262) 2-24-16

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

САТЫШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422070, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Сатышавылы, Ленин урамы, 17Б йорт
тел. (8262) 2-24-16

e-mail: Sat.sab@tatar.ru


РЕШЕНИЕ
23.10.2024

КАРАР
№22

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Сатыш авыл җирлеге Советының 17.12.2021 №31 карары белән кабул ителгән муниципаль берәмлек Уставын "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, №131 Федераль законга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Сатыш авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын раслау турында 17.12.2021 елгы №31 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Сатыш авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлегендә җәмәгать тыңлауларын һәм җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 06.03.2023 елның №6 карары белән расланган тәртиптә 2024 елның 4 декабрендә ачык тыңлаулар үткәрергә 09.00 сәгатьтә Сатыш мәдәният йортының: ТР, Саба районы, Сатыш авылы, Ленин ур., 17Б адресында.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Сатыш авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне 2024 елның 3 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Сатыш авыл җирлеге Советына җибәрергә.

5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты турындагы карарны махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарны, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен бастырып чыгарырга:

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Сатыш авылы, Ленин ур., 17Б йорт; Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Аккүл Бигәнәй авылы, М.Җәлил урамы, 24 нче йорт; Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Мамалай авылы, Чапай урамы, 6 нче йорт.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Башлыгы — Ф.Ф.Шафигуллин

СОВЕТ САТЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ИНН 1635001023 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САТЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы Сатыш авыл
җирлеге Советы карары белән
23.10.2024 №22

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының
Сатыш авыл җирлеге Уставына кертелә торган
үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты

1. 5 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 21) пунктча өстәргә:
«21) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә граждannар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

2.19 статьяның 5 пунктының икенче абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен «1 – 7 һәм 9.2 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

2. 34 статьяның 1 пунктындагы 26) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«26) матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру;»;

3. 41 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12.1 пунктчасы өстәргә:
«12.1) аның чит ил агенты статусын алуы;».

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы Сатыш авыл
җирлеге Советы карары белән
23.10.2024 №22

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Сатыш авыл җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына граждannар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Сатыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Сатыш авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 422070, ТР, Саба районы, Сатыш авылы, Ленин ур., 17Б йорт, язма рәвештә Сатыш авыл җирлеге башлыгына.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.42 сәгатькә кадәр җирлекнең махсус мәгълүмат стендларында игълан ителгән яисә хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылган көннән алып кабул ителә.

2. Җәмәгать тыңлауларында чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 422070, ТР, Саба районы, Сатыш авылы, Ленин ур., 17Б йорт (конвертта «Устав турында фикер алышу»тамгасы белән).

Сатыш авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ф.Шафигуллин